КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 сентябрь г.Казань № 852

2020 елда югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларны эш белән тәэмин итү буенча ярдәм чаралары күрсәтүне тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруны тәэмин итү өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына субсидия рәвешендәге грантны гамәлгә куярга.

2. Бу карарга теркәлгән 2020 елда югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен расларга.

3. Бу карарны куллану буенча аңлатмалар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 21 сентябрь, 852 нче
карары белән расланды

## 2020 елда югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип 2020 елда югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны (алга таба – чаралар) тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендәге грант (алга таба – грант) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 533 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы кысаларында көндезге (уку йортына йөреп) уку формасы буенча югары белем бирү программалары (бакалавриат, специалитет, магистратура) буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру чараларын тормышка ашыру максатларында иң күбе өч айга бирелә.

1.3. Бу Тәртип максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

грант алырга теләүче – Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып бара торган, югары белем бирүче мәгариф оешмасында булдырылган эш урыннарына студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруны тәэмин итә торган әлеге югары белем бирүче мәгариф оешмасы;

грант алучы – сайлап алуда җиңүче дип танылган грант алырга теләүче;

комиссия – 2020 елда студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына субсидия рәвешендә грантлар бирүгә заявкаларны карап тикшерү комиссиясе.

1.4. Грант бирү Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.5. Грант түләү акчасының иң чик күләме 6 835,5 мең сум тәшкил итә.

1.6. Грант, грант алырга теләүчедә булдырылган эш урыннарына студентларны билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт шартнамәләре буенча эшкә урнаштыруга бәйле рәвештә, хезмәт өчен түләү һәм мәҗбүри пенсия иминләштерүенә, мәҗбүри социаль иминләштерүгә, мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә бирелә.

1.7. Грант бирү грант алучы тарафыннан чараны грант акчасының кимендә 100 проценты күләмендә финанслашуны тәэмин итү шарты белән гамәлгә ашырыла.

## II. Грант алырга теләүчеләрне сайлап алуны үткәрү тәртибе

2.1. Министрлык сайлап алуны үткәрү турында карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән өч көн эчендә үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ( алга таба – рәсми сайт) сайлап алуны үткәрү турында белдерү, грант бирү өчен документлар кабул итү шартлары һәм вакытлары турында мәгълүмат (2020 елда студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына субсидия рәвешендә грантлар бирүгә заявкаларны (алга таба – заявкалар) кабул итә башлау һәм кабул итеп бетерү даталары турында мәгълүматларны кертеп), элемтәгә керү өчен телефон номерлары турында мәгълүматлар урнаштыра.

2.2. Заявкаларны кабул итү рәсми сайтта сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Заявкаларны кабул итү вакыты башланганга кадәр яки заявкаларны (шул исәптән почта аша) кабул итү вакыты тәмамланганнан соң Министрлыкка килгән заявкалар теркәлми, карап тикшерелми һәм кире кайтарылмый.

2.3. Грант аны бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килә торган грант алырга теләүчегә бирелә:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаган, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, грант алырга теләүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки

территория торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булып тормаган;

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы булмаган;

грант алырга теләүчегә элек бирелгән бюджет акчасын (грантларны, субсидияләрне) максатчан файдаланмау һәм (яки) нәтиҗәсез файдалану фактлары булмаган;

министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алырга теләүченең грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга грант алырга теләүченең ризалыгы булган;

грант алырга теләүчегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органның әлеге орган бланкында рәсмиләштерелгән сайлап алуда катнашуга ризалыгын раслау кәгазен тапшырган.

2.4. Грант алу өчен грант алырга теләүчеләрне сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

грант алырга теләүченең студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булу;

планлаштырыла торган заявка бирү датасына кадәр кимендә ике ел Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын тормышка ашыруда катнашу;

уку-укытуның барлык формалары буенча югары белем бирү программалары нигезендә белем алучыларның гомуми контингенты кимендә 20 мең кеше булу;

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны финанслашуны грант күләменнән кимендә 100 процент күләмендә тәэмин итүгә әзерлек булу.

2.5. Сайлап алуда катнашу өчен грант алырга теләүче тарафыннан Министрлыкка бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча заявка, шулай ук грант алырга теләүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан расланган түбәндәге документлар тапшырыла:

2020 елда кимендә 250 студентны вакытлыча эшкә (иң күбе өч айга) урнаштыруны оештыру программасы (алга таба – программа);

студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру тәҗрибәсе турында аналитик мәгълүмат (биш биттән дә ким булмаган күләмдә);

программаның акчаны тоту юнәлешләрен һәм күләмнәрен (финанслау күләмнәрен) күздә тота торган бюджеты;

грант алырга теләүченең студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булуын раслый торган документлар;

грант алырга теләүченең гамәлгә кую документлары, шулай ук закон белән билгеләнгән тәртиптә расланган аларга барлык үзгәрешләрне кертү турындагы документлар күчермәләре;

үткән финанс елы өчен бухгалтерлык балансы күчермәләре;

бирелә торган гранттан кимендә 100 процент күләмендә чараны финанслашу буенча ирекле рәвештә язылган гарантия хаты;

килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә грант алырга теләүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы куелган, мөһер белән расланган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар

нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазе (ирекле формада);

килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә грант алырга теләүченең үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавын, грант алырга теләүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын раслый торган белешмә кәгазе;

грант алырга теләүче тарафыннан элек бирелгән бюджет акчасын (грантлар, субсидияләр) максатчан файдаланмау һәм (яки) нәтиҗәсез файдалану фактлары булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә грант алырга теләүченең бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемнәрен, аларны раслау турында норматив хокукый актлар реквизитларын күрсәтеп, Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыруда заявка бирергә планлаштырыла торган датага кадәр кимендә ике ел катнашу турында мәгълүмат;

соңгы хисап датасына рәсми статистик хисап формалаштырылган белем алучылар контингенты турында мәгълүмат;

министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алырга теләүченең грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга грант алырга теләүченең ризалыгын раслый торган белешмә кәгазе;

грант алырга теләүчегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органның әлеге орган бланкында рәсмиләштерелгән сайлап алуда катнашуга ризалыгы.

Грант алырга теләүче үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан заявка бирү көненә кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә бирелгән заявка бирүче турындагы мәгълүматлар белән өземтә күчермәсе;

салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турында белешмә кәгазе.

Грант алырга теләүче бу пунктның унсигезенче һәм унтугызынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.6. Бу Тәртипнең 2.5 нче пунктында каралган документлар белән заявка Министрлыкка почта аша җибәрелә яки грант алырга теләүченең вәкаләтле заты тарафыннан тапшырыла.

Министрлык грант алырга теләүче тарафыннан заявкаларны кабул итүнең билгеләнгән вакытында кертелгән заявканы кабул итә һәм кергән көнендә

Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча төзелгән заявкаларны теркәү журналында, заявканың керү датасын һәм вакытын күрсәтеп һәм заявкага теркәүгә алуның тәртип санын биреп, теркәүгә ала һәм грант алырга теләүчегә, аны алу датасын һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, расписка кәгәзе бирә. Заявка почта аша кергәндә ул кергән көнендә заявкаларны теркәү журналында теркәлә, анда Министрлыкка почта аша керү датасы һәм вакыты күрсәтелә. Бу очракта, заявканы алу датасы һәм вакыты һәм бирелгән теркәү номеры күрсәтелгән расписка кәгазе грант алырга теләүчегә почта аша йә заявкада күрсәтелгән башка ысул белән җибәрелә.

2.7. Министрлык заявканы теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә тапшырылган документларны, заявка керү датасыннан һәм вакытыннан чыгып, алар кергән чират тәртибендә карап тикшерә һәм грант алу өчен сайлап алуда катнашырга рөхсәт бирү йә анда катнашырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

2.8. Грант алырга теләүчегә грант алу өчен сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

грант алырга теләүченең бу Тәртипнең 2.3 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

грант алырга теләүче тарафыннан документларның аларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң тапшырылуы.

Грант алу өчен сайлап алуда катнашудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык тиешле карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә грант алырга теләүчегә, баш тартуның нигезен күрсәтеп, язма хәбәр җибәрә.

2.9. Әгәр дә теркәлгән документлары белән бер генә заявка да бу Тәртип таләпләренә туры килмәсә, Министрлык, заявкаларны кабул итә башлаган датага кадәр кимендә 10 эш көне кала, рәсми сайтта заявкаларны кабул итә башлау һәм кабул итеп бетерү турында яңадан мәгълүмат урнаштыруны гамәлгә ашыра.

2.10. Сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителгән грант алырга теләүчеләрнең заявкалары бер эш көне эчендә Министрлык тарафыннан комиссиягә тапшырыла.

2.11. Комиссия составы Министрлыкның хокукый акты белән раслана, аның комиссия рәисе, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары билгеләнә.

Комиссия Министрлык хезмәткәрләре арасыннан төзелә. Комиссия составына килешү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка кызыксынучы башкарма органнары һәм федераль башкарма хакимият органнары вәкилләре кертелергә мөмкин.

Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның карарын раслый.

Комиссия секретаре комиссия рәисе кушуы буенча комиссия утырышын әзерләүне оештыру функцияләрен гамәлгә ашыра.

Комиссия утырышы анда комиссия составының кимендә өчтән ике өлеше катнашканда тулы хокуклы дип санала.

2.12. Комиссия заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявкаларны түбәндәге критерийлар нигезендә балл системасы буенча бәяләүне гамәлгә ашыра:

| Т/с | Бәяләү критерийлары | Бәяләү, баллар |
|---|---|---|
| 1. | Грант алырга теләүченең студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булу | кимендә 250 – 0;<br>250 һәм<br>аннан да күбрәк – 5 |
| 2. | Планлаштырыла торган заявка бирү датасына кадәр кимендә ике ел Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыруда катнашу | катнашмау – 0;<br>катнашу – 5 |
| 3. | Уку-укытуның барлык формалары буенча югары белем бирү программалары нигезендә белем алучыларның гомуми контингенты булу, кеше | 20 000нән кимрәк – 0;<br>20 000 – 24 999 – 2;<br>25 000 – 35 000 – 3;<br>35 000нән күбрәк – 5 |
| 4. | Бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны финанслашуны грант күләменнән кимендә 100 процент күләмендә тәэмин итүгә әзерлек булу | булмау –0;<br>булу – 5 |

2.13. Заявкаларны бәяләү йомгаклары буенча комиссия бу Тәртипнең 2.12 нче пунктында каралган вакыт эчендә балл системасы буенча заявкаларның рейтингын төзи. Иң күп балл җыйган заявкага беренче номер бирелә.

Әгәр дә берничә заявканың җыйган баллары бертөрле булса, беренче тәртип саны заявкаларның башкаларыннан иртәрәк кергән заявкага бирелә.

Заявкалар рейтингы комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул бу Тәртипнең 2.12 нче пунктында каралган вакыт чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә әзерләнә һәм комиссия рәисенең имзасы куела һәм Министрлыкка тапшырыла.

Министрлык заявкалар рейтингын алган көннән өч көн эчендә рәсми сайтта сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүмат, шул исәптән сайлап алуда катнашучылар, рейтинг һәм (яки) сайлап алу критерийлары буенча бәяләүләр, бирелә торган грантның күләме турында мәгълүмат урнаштыра.

2.14. Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Министрлык эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә грант алу өчен сайлап алу нәтиҗәләре буенча грант алырга теләүчегә грант бирү турында яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

грант алырга теләүченең бу Тәртипнең 2.3 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

грант алырга теләүче тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 2.5 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алырга теләүче тарафыннан заявкадагы һәм бу Тәртипнең 2.5 нче пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

Министрлыкның хокукый акты белән кабул ителгән грант бирү турындагы карар килешү төзү өчен нигез булып тора.

Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамәләр Министрлык тарафыннан грант алырга теләүчеләргә тиешле карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә язма рәвештә җибәрелә. Кабул ителгән карар турындагы мәгълүмат рәсми сайтта әлеге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә урнаштырыла.

## III. Грант бирү тәртибе

3.1. Министрлык тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлык грант алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә грант күләме, аның максатчан билгеләнеше, грантлар бирү нәтиҗәсе мәгънәләре, грант бирү вакытлары һәм шартлары, өстәмә хисаплылык вакытлары һәм формасы (кирәк булганда), Министрлыкның һәм дәүләт финанс контроле органнарының грант алучы тарафыннан грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләр үткәрүгә хокукы, грантны кире кайтару очраклары, хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калган өлешләрен агымдагы финанс елында кире кайтару турындагы нигезләмә, грантны (грантның калган өлешләрен) кире кайтару тәртибе һәм вакытлары, Министрлык, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга грант алучы ризалыгы, грант алучының алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуын (Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш) тыю, килешү шартларын бозган һәм грант алучы тарафыннан килешүнең грантны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны күздә тота торган шартларын үтәмәгән өчен җаваплылык, грант алучы тарафыннан бу Тәртипнең һәм төзелә торган килешүнең шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр карала.

3.2. Грант алучыга бирелә торган грант күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Ч \times N \times P \times К,$$

монда:

Ч – эшкә урнаштырырга планлаштырыла торган студентлар саны (иң күбе 250 кеше);

N – бер студентның 1 айга мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенә, мәҗбүри социаль иминиятләштерүгә, мәҗбүри медицина иминиятләштерүенә иминият кертемнәре суммасына арттырылган 14 мең сум күләмендә хезмәте өчен түләү чыгымнары;

Р – студентларга эш хакын түләү айлары саны (иң күбе өч ай);

К – Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның 0,5 гә тигез булган өлеше.

3.3. Грант бирү нәтиҗәсе булып эшкә урнаштырылган студентлар саны тора.

3.4. Министрлык тарафыннан грант акчасын күчерү килешү төзегән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның территориаль органында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында яки аның территориаль органнарында ачылган грант алучының шәхси счетларына йә Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетларына гамәлгә ашырыла.

## IV. Хисаплылыкка карата таләпләр

4.1. Грант алучы, 2020 елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча, түбәндәге документларның үзе раслаган күчермәләрен теркәп, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча грант бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра:

студентлар белән билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт шартнамәләре;

эшкә кабул итү турында боерыклар;

эш вакытын исәпкә алу табеле;

исәп-хисап ведомосте (эш хакының исәпләнгән суммасы турында);

иракле рәвештә төзелгән бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре буенча исәпләүләрнең исәп-хисабы;

түләү ведомосте (эш хакының түләнгән суммасы турында) яки студентларның кредит оешмаларындагы шәхси счетларына эш хакын суммасын күчерү турында түләү йөкнамәсе;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен күчерү турында түләү йөкнамәсе.

4.2. Грант бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшырганда грант алучы Министрлыкка кимендә биш биттән торган чараны тормышка ашыру тәҗрибәсе турында аналитик мәгълүмат җибәрә.

Аналитик мәгълүмат Министрлык тарафыннан аналитик, мәгълүмати, методик материаллар әзерләгәндә кулланылырга мөмкин.

## V. Грант бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүдә тоту тәртибе һәм грант бирү тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

5.1. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен җаваплылык грант алучыга йөкләнә.

5.2. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучы тарафыннан грант бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.3. Грант түбәндәгеләр ачыкланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш:

гранттан максатчан файдаланмаганда;

грант алучы тарафыннан аны биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылганда;

грант бирү нәтиҗәләренең план буенча мәгънәләренә ирешелмәгәндә.

5.4. Хисап финанс елы йомгаклары буенча грант бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{возвр}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{возвр} = \left(1 - \frac{P_{факт}}{P_{план}}\right) \times S,$$

монда:

$P_{план}$ – грант бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе;

$P_{факт}$ – грант бирү нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе;

S – чараны тормышка ашыру өчен грант алучыга бирелгән грант күләме.

5.5. Килешүдә каралган очракларда, хисап финанс елында грантның файдаланылмый калган өлешләре грант алучы тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

5.6. Грант алучы тарафыннан бу Тәртипнең 5.3 һәм 5.5 нче пунктларында күрсәтелгән грантны кире кайтару вакытлары бозылганда, Министрлык грантны кире кайтару вакыты чыккан көннән 30 көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

5.7. Законнар нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучының грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.8. Грант алучының гранттан максатчан файдалануын тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2020 елда югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

2020 елда югары белем бирү программалары буенча
белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән
чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирүгә
заявка

I. Заявка бирүче оешма

1.1. Оешма исеме_______________________________________________
1.2. Оешманың кыскартылган исеме___________________________________
1.3. ОГРН ____________________________________________________________
1.4. ИНН _____________________________________________________________
1.5. КПП _____________________________________________________________
1.6. Оешманы дәүләт теркәвенә алу датасы ____________________________
1.7. Оешманың адресы ___________________________________________________
(оешманың дәүләт теркәвенә алу урыны күрсәтелә: почта индексы,
_____________________________________________________________________________
Татарстан Республикасы, муниципаль район (Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре шәһәр округларыннан башка),
_____________________________________________________________________________
шәһәр (торак пункт), урам, йорт номеры, корпус номеры (булганда), офис (фатир) номеры)

1.8. Факттагы адресы _________________________________________________
(оешманың факттагы булу урыны күрсәтелә: почта индексы,
_____________________________________________________________________________
Татарстан Республикасы, муниципаль район (Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре шәһәр округларыннан башка),
_____________________________________________________________________________
шәһәр (торак пункт), урам, йорт номеры, корпус номеры (булганда), офис (фатир) номеры)

1.9. Элемтә керү өчен телефоннар +7______________________________________
(оешма белән элемтәгә керергә мөмкин булган
_____________________________________________________________________________
һәм ачык рәвештә, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә)
_____________________________________________________________________________
урнаштырылачак телефон номерлары күрсәтелә

1.10. Юридик яктан әһәмиятле хәбәрләрне оешмага җибәрү өчен электрон почта адресы _______________________________________________________________
(юридик әһәмияткә ия булган хәбәрләрне һәм документларны җибәрергә мөмкин булган электрон почта адресы күрсәтелә)

1.11. Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)
_______________________________________________________________
11.1.1. Оешма җитәкчесе вазыйфасы _____________________________________
1.11.2. Оешма җитәкчесенең элемтәгә керү өчен телефоны +7_________________
1.11.3. Җитәкченең электрон почта адресы ______________________________
(электрон почта адресы булганда күрсәтелә, булмаганда «Юк» дип куела)

1.12. Баш бухгалтер (бухгалтер)_____________________________________
(баш бухгалтер (бухгалтер) яки оешмада тиешле функцияләрне
_______________________________________________________________
башкаручы зат булганда күрсәтелә, булмаганда, «Юк» дип куела)

1.12.1. Баш бухгалтерның (бухгалтерның) элемтәгә керү өчен телефоны +7_________
1.12.2. Баш бухгалтерның (бухгалтерның) электрон почта адресы _______________
(электрон почта
_______________________________________________________________
адресы булганда күрсәтелә, булмаганда «Юк» дип куела)

1.13. Оешмасы структурасында белем алучыларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш урыннары бирүне тәэмин итүче һәм эшләүче структур бүлекчәсе исеме
_______________________________________________________________
(булмаган очракта, «Юк» дип куела)

1.14. Заявка датасына кадәр Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын тормышка ашыруда катнашу чоры ______________________________
(булмаган очракта, «Юк» дип куела)

1.15. Уку-укытуның барлык формалары буенча югары белем бирү программалары нигезендә белем алучыларның гомуми контингенты _____________________

## II. Көндезге (уку йортына йөреп) уку формасы буенча югары белем программалары (бакалавриат, специалитет, магистратура) нигезендә белем алучы студентларны билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт шартнамәсе буенча вакытлыча эшкә урнаштыру тасвирламасы (алга таба – проект)

2.1. Проектны тормышка ашыра башлау _________________________________
(ае, елы)

2.2. Проектны тормышка ашырып бетерү ________________________________
(агымдагы елның 31 декабрьдән дә соңга калмыйча, ае, елы )

## III. Проблематиканы һәм социаль әһәмиятлелекне нигезләү

_______________________________________________________________
(проектны хәл итүгә юнәлдереләчәк гамәлдәге вәзгыятьне һәм проблеманы чагылдыра торган
_______________________________________________________________
текст презентациясе, эчтәлеге һәм иң мөһим көтелә торган нәтиҗәләре (иң күбе 600 символ))

## IV. Проектның максаты

_______________________________________________________________
(оешманың эшчәнлеге ирешергә дип юнәлдерелгән,
_______________________________________________________________
тормышка ашырырга дип грант соралган бер максат булдырыла)

## V. Проектның бурычлары

______________________________________________________________________________

## VI. Проектны тормышка ашыруның көтелә торган микъдари нәтиҗәләре

______________________________________________________________________________

## VII. Проектның көтелә торган сыйфаты ягыннан нәтиҗәләр

______________________________________________________________________________

(проектны тормышка ашыру чорында ирешергә планлаштырылган,

______________________________________________________________________________

сан мәгънәләрендә үлчәнми торган нәтиҗәләр күрсәтелә)

2020 елда югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

2020 елның ______________ хәленә карата югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны вакытлыча эшкә урнаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
хисап

Оешма исеме: ___________________________________________

| Т/с | Грант бирү нәтиҗәсенең исеме | Үлчәү берәмлеге | | Грант бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата грант бирү нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Оешма җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ________________________ ____________ ________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.

Башкаручы _______________________ __________________________ _______________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (телефоны)

2020 ел, «__» _________

_____________________________________________